РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ЗАМЕСТИТЕЛЬ ГЛАВЫ**
**посёлка городского типа**
**КАМСКОЕ УСТЬЕ**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**Кама Тамагы**
**шәһәр тибындагы поселогы**
**БАШЛЫГЫ УРЫНБАСАРЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 24 ноябре № 13

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлары Татарстан Республикасы законнары 35-ТРЗ, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлеге Уставы нигездә **карар бирәм**:

1.Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын этаплап билгеләргә:

- 2020 елның 4 декабрендә 13.00 сәгатькә Комаров ур., 1,3,5,2,7 йортлар өчен;
-2020 елның 4 декабрендә 15.00 сәгатькә Комаров ур., 4,9,9а,9б,19,17,14 йортлар өчен;
- 2020 елның 4 декабрендә 17.00 сәгатькә Комаров ур., 12,10,8,13,13а,15 йортлар өчен;
-2020 елның 4 декабрендә 18.00 сәгатькә Комаров ур., 18.20,21,22,23 йортлар өчен;
-2020 елның 10 декабрендә 13.00 сәгатькә Дзержинский, Островский урамнары өчен;
-2020 елның 10 декабрендә 15.00 сәгатькә Татарстан, С.Сайдашев, Г.Ибраһимов, Яшьләр, М. Җәлил, Газ, К. Маркс ур. 113-154 йортлары өчен;

- 2020 елның 11 декабрендә 15.00 сәгатькә  Чирков, Суворов, 1-Май, Некрасов, Коммуналь, Ленин, Кыр, Вахитов, Гагарин, Светлая, Нариманов урамнары өчен;
-2020 елның 14 декабрендә 13.00 сәгатькә Гоголя, Октябрь, Г.Тукай, Зур Идел, Дуслык , Пионер урамнары өчен;
-2020 елның 14 декабрендә 15.00 сәгатькә К.Маркс, Комсомол, Маяковский, Ленин, Тынычлык, Киров, Совет, Калинин урамнары өчен;
- 2020 елның 15 декабрендә 13.00 сәгатькә Есенин, Лисин, И. Гази, Б. Урманче, Т. Миңнуллин, Әблиев урамнары өчен;
- 2020 елның 15 декабрендә 15.00 сәгатькә Елга, Чокыр аръягы, Үзәк, Елга арты, 9 Май, Яңа, Томбай, Г. Камал урамнары өчен;
-2020 елның 15 декабрендә 17.00 сәгатькә Болын, С. Садыкова, Кояшлы, Г. Сөнгати, Ф. Халиди урамнары өчен.

2.Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2021 елда  “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданнан, ташламалы категорияләрдән тыш (беренче төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, көндезге формада белем алучы студентлар) 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтү белән килешәсезме?:

- Кооператив, Тынычлык, Щербаков, Яшьләр урамнары буенча поселок эчендәге юлларны ремонтлау (чокыр ремонты һәм вак таш салу, сатып алу, ташу, вак таш җәю, асфальт җәю, эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) ;

- Дзержинский, Комаров урамнары буенча ишегалларын төзекләндерү (материал сатып алу, эшләр һәм хезмәтләр өчен смета буенча түләү);

- Маяковский, Дзержинский урамнары буенча куаклар һәм агачлар кисү, чокыр аша Көньяк урамга юл, «Рандеву» кафесыннан Көньяк околицага кадәр юл буйларын, (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

« РИЗА»                                                        «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы Кама Тамагы штп, Совет ур., 11, ҖҮИ бинасы, Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Кама Тамагы штп, К. Маркс ур., 105 нче йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән, шулай ук «Интернет»

мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында 5 (биш) көн эчендә урнаштырырга.

4.Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Башлык урынбасары Р.Х. Дәүләтшин